КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 август г.Казань № 989

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 21 май, 413 нче; 2020 ел, 1 сентябрь, 772 нче; 2020 ел, 23 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 821 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1021 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 15 июнь, 566 нчы; 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче; 2023 ел, 11 март, 232 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VIII бүлектә:

исемендә татар текстында «баш бухгалтерның» сүзләреннән соң «һәм тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча директор киңәшчесенең» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 10 – 12 пунктлар өстәргә:

«10. Тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча директор киңәшчесенең вазыйфаи оклады ($O_{d_s}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$O_{d_s} = O_{b_s} \times S,$$

монда:

$O_{b_s}$ – тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча директор киңәшчесенең база окладыкүләме 18 398 сум күләмендә билгеләнә;

S – фактта эшләнгән вакыт (ставка).

11. Хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча директор киңәшчесенә бирелә ($B_{sr_s}$) һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{sr_s} = O_{d_s} \times D_{sr_s},$$

монда:

$O_{d_s}$ – тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча директор киңәшчесенең вазыйфаи оклады күләме;

$D_{sr_s}$ – тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча директор киңәшчесенең хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү күләме 100 процентка тигез итеп алына.

12. Компенсация характерындагы түләүләр тәрбия бирү һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү буенча директор киңәшчесе өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.».

2. Бу карар 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин